ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

10.01.2022 г. Заинск № 04

**«Зәй муниципаль районы территориясендә, авария хәлләрен электрон модельләштерүне кулланып, авария нәтиҗәсендә килгән зыянны бетерү буенча гамәлләр планын раслау турында»**

Зәй муниципаль районы территориясендә җылылык белән тотрыклы тәэмин итү максатында, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законнар, «Җылылык белән тәэмин итү турында» 2010 елның 27 июлендәге 190-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы территориясендә оператив мәгълүмат алу һәм җылылык белән тәэмин итү объектларының һәм системаларының ышанычлылыгын тикшереп тору максатында, РФ Энергетика министрлыгының «Ягулык чорына әзерлекне бәяләү кагыйдәләрен раслау турында» 2013 елның 12 мартындагы 103 номерлы боерыгын үтәү йөзеннән, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты

**карар бирә:**

1. Зәй муниципаль районы территориясендә, авария хәлләрен электрон модельләштерүне кулланып, авария нәтиҗәсендә килгән зыянны бетерү буенча гамәлләр планын кушымта нигезендә расларга.
2. Әлеге карарны муниципаль районның рәсми сайтта урнаштырырга.
3. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **Э.Э. Галеев**

8(85558)7-08-18
Э.Н. Кулагина

Кушымта
Татарстан Республикасы
Зәй муниципаль районы
Башкарма комитетының
10.01. 2022 ел
04 номерлы карары белән
расланган.

# Зәй муниципаль районы территориясендә, авария хәлләрен электрон модельләштерүне кулланып, авария нәтиҗәсендә килгән зыянны бетерү буенча гамәлләр планы

## I. Гомуми нигезләмәләр

1. Авария хәлләрен электрон модельләштерүне кулланып, авария нәтиҗәсендә килгән зыянны бетерү буенча гамәлләр планы (алга таба – план) Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан ресурслар белән тәэмин итүче оешмалар, идарәче компанияләр, торак милекчеләре ширкәтләре, җылылык энергиясен кулланучыларның Зәй муниципаль районының җылылык белән тәэмин итү системаларында авария нәтиҗәләрен бетерүгә бәйле мәсьәләләрне хәл иткәндә эшчәнлеген координацияләү максатында эшләнде.

2. Планда авария хәлләре дигәндә, җылылык белән тәэмин итү объектында һәм (яки) җылылык куллану җайланмасында җылылык белән тәэмин итү объектындагы корылмаларны һәм (яки) җылылык белән тәэмин итү объектындагы техник җайланмаларны (җайланмаларны) җимерүгә яки зыян китерүгә, контрольгә алынмаган шартлауга һәм (яки) куркыныч матдәләр чыгуга, җылылык белән тәэмин итү объектларының һәм (яки) җылылык кулланучы җайланмаларның билгеләнгән технологик эш режимыннан тайпылуга, җылылык энергиясен (егәрлек) куллану режимы тулысынча яки өлешчә чикләнүгә китергән технологик җитешсезлекләр аңлашыла.

3. Җылылык челтәрләрендә һәм җылылык энергиясе чыганакларында аварияле хәлләрнең (гадәттән тыш хәлләр) мөмкин булган нәтиҗәләре исемлегенә түбәндәгеләр керә:

халыкны, социаль өлкә объектларын җылылык белән тәэмин итүнең кыска вакытлы бозылуы;

халыкны, социаль өлкә объектларын җылылык белән тәэмин режимы тулысынча тукталу;

җылылык белән тәэмин итү объектлары җимерелү (казаннар, җылылык челтәрләре,котельныйлар);

тәүлек буена һәм аннан да күбрәккә җылылык белән тәэмин ителмәү.

4. Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының төп бурычы булып халыкны һәм социаль объектларны җылылык белән тәэмин итүне оештыру тора.

5. Җылылык белән тәэмин итү оешмаларының бурычлары:

кулланучыларны җылы белән тотрыклы тәэмин итүне тәэмин итү;

энергия чыганакларының кирәкле параметрларын саклап калу;

биналарда нормаль температура режимын тәэмин итү;

кизү-диспетчерлык хезмәтенең тәүлек буе эшләвен оештыру (алга таба – КДХ (ДДС));

энергия ресурсларының яисә ягулыкның вакытлыча җитешмәве очрагында технологик хокук бозулар, чикләүләр һәм туктатылулар вакытына гамәлләрнең оператив планы кертелгән инструкцияләрне эшләү һәм раслау;

инженер-техник челтәрләрдә технологик хокук бозулар яисә авария очраклары турында мәгълүмат алганда яисә энергияне сак тотуның билгеләнгән режимнары бозылганда үз вәкилләренең урынга чыгуын тәэмин итү;

хезмәт күрсәтелә торган инженерлык челтәрләрендә аварияне бетерү эшләрен минималь срокларда башкару;

куркыныч зоналарны саклау буенча чаралар күрү (һәлакәт урынын киртәләргә, җәяүлеләрнең һәм транспорт чараларының куркыныч зонага очраклы эләгүен кисәтү максатларында билге куярга, даими күзәтүне тәэмин итәргә);

Зәй муниципаль районының “УГЗ ИК ЗМР” МКУ Бердәм кизү-диспетчерлык хезмәте диспетчерына (алга таба - ЕДДС тел. 7-40-01,112), ТР ЗМР "ТКХ һәм технологик контроль үзәге" МУП (тел. 7-16-16), Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының ТКХ, төзелеш, транспорт, энергетика, элемтә һәм юл хуҗалыгы бүлегенә (тел. 7-08-18) җылылыкны туктату яки чикләү, сәбәпләрен күрсәтеп, өзеклекнең вакыты, күрелә торган чаралар һәм өзеклекне бетерү сроклары, нинди көчләр һәм чаралар кулланылачагы турында хәбәр ителә.

6. Җылылык белән тәэмин итү оешмаларының коммуналь хезмәтләрне күрсәтүчеләр һәм кулланучылар белән үзара мөнәсәбәтләре алар арасында төзелгән шартнамәләр һәм коммуналь хезмәтләр күрсәтү өлкәсендә гамәлдәге законнар белән билгеләнә. Коммуналь хезмәтләрне күрсәтүчеләрнең, кулланучыларның һәм җылылык белән тәэмин итү оешмасының җаваплылыгы инженерлык челтәрләренең нинди баланста булуы белән билгеләнә һәм инженерлык челтәрләренең кем балансында булуы һәм якларның эксплуатация җаваплылыгы турында шартнамәгә кушып бирелә торган актта теркәлә.

7. Коммуналь хезмәт күрсәтүне башкаручылар җылылык кулланучы системаларга вакытында һәм сыйфатлы техник хезмәт күрсәтүне һәм ремонтлауны, шулай ук җылылык энергиясеннән файдалану килешүе нигезендә җылылыкның егәрлеге яки җылылык белән тәэмин итү чыганакларында ягулык җитмәү вакытында җылылык куллану җайланмаларын чикләү һәм өзү графигын эшләү һәм үтәүне тәэмин итәләр.

8. Коммуналь хезмәтләрдән файдаланучылар җылылык системаларына техник хезмәт күрсәтү һәм ремонт ясау өчен шартнамәләр төзелгән махсус оешма хезмәткәрләренең тәүлекнең теләсә кайсы вакытында объектларга керүен тәэмин итәләр.

## II. МАКСАТЛАР ҺӘМ БУРЫЧЛАР

9. Планның максатлары булып тора:

социаль өлкә объектлары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген, тотрыклылыгын һәм ышанычлылыгын арттыру;

торак-коммуналь хуҗалык объектларында технологик җитешсезлекләрне һәм авария хәлләрен бетерү буенча көчләрне мобилизацияләү;

торак-коммуналь билгеләнештәге объектларда технологик җитешсезлекләрне һәм авария ситуацияләрен тиеш булган дәрәҗәгә киметү;

торак-коммуналь хуҗалык объектларында технологик җитешсезлекләрне һәм авария хәлләре барлыкка килү нәтиҗәләрен минимальләштерү.

10. Планның бурычлары булып тора:

торак-коммуналь хуҗалык объектларында авария хәлләрен бетерү буенча оператив штабларны әзерлек хәленә китерү, кирәкле көчләрне һәм чараларны концентрацияләү;

аварияле хәлләрне локальләштерү һәм бетерү эшләрен оештыру;

аварияле хәлләрне локальләштерү һәм бетерү эшләрен матди-техник ресурслар белән тәэмин итү;

авария хәле барлыкка килү һәм бетерү барышында халыкның тормыш-көнкүрешен, социаль һәм мәдәни өлкә объектларының тотрыклы эшләвен тәэмин итү.

## III. ЭШЛӘРНЕ ОЕШТЫРУ

11. Җылылык белән тәэмин итү объектларында аварияне бетерү белән идарә итү.

Аварияне бетерү эшләрен муниципаль дәрәҗәдә координацияләүне Зәй муниципаль районының гадәттән тыш хәлләр һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү комиссиясе - объектны эксплуатацияләүне гамәлгә ашыручы оешма җитәкчесе башкара.

Көндәлек идарә органнары булып тора:

муниципаль дәрәҗәдә – гадәттән тыш хәл шартларында авария-коткару һәм башка көчләр белән оператив идарә итү, муниципаль берәмлек территориясендә урнашкан оешмаларның юл-транспорт һәлакәтләренә оператив җавап бирү һәм уртак гамәлләрен координацияләү мәсьәләләре буенча БКДХ (ЕДДС) (алга таба – ГХ (ЧС)).

объект дәрәҗәсендә - оешманың кизү-диспетчерлык хезмәте.

Көндәлек идарә органнарын урнаштыру техник идарә итү чаралары, элемтә, хәбәр итү һәм яшәешне тәэмин итү чаралары белән тәэмин ителгән, даими кулланылышка әзер торышта булган стационар идарә пунктларында гамәлгә ашырыла.

Көндәлек идарә органнарын урнаштыру техник идарә итү, элемтә, хәбәр итү һәм көнкүрешне тәэмин итү чаралары белән тәэмин ителгән, файдалануга даими әзерлектә булган стационар идарә пунктларында гамәлгә ашырыла.

12. Җылылык белән тәэмин итү объектларында аварияләрне бетерү өчен көчләр һәм чаралар.

Җылылык белән тәэмин итү объектларында көндәлек эшчәнлек режимында белгечләрнең дежур торуы гамәлгә ашырыла.

Аварияне ликвидацияләү эшләренә әзерлек вакыты - 45 мин.

Аварияләрне бетерү өчен билгеләнгән тәртиптә булдырыла һәм кулланыла:

авария-торгызу эшләрен норматив срокларда башкаруны тәэмин итәргә тиешле резерв фондлары;

аварияле зонадагы кулланучыларны күчерү буенча үз вакытында карар кабул итү максатыннан оператив мәгълүматларны кертү өчен җылылык белән тәэмин итү схемасының электрон моделе.

13. Җылылык белән тәэмин итү объектларында аварияләрне бетерү буенча гамәлләр тәртибе.

Аварияләнең сәбәпләре, масштабы һәм килеп чыгарга мөмкин булган нәтиҗәләре, ремонт-торгызу эшләренең планлаштырылган вакыты, җәлеп ителә торган көчләр һәм чаралар, аварияләнең характеры буенча аны муниципаль яки объект дәрәҗәсенә кертү турында эшләр җитәкчесе гадәттән тыш хәл килеп чыкканнан соң 10 минут эчендә БКДХ (ЕДДС) диспетчерына хәбәр итә.

Авария нәтиҗәләрен бетерү Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының ягулык-энергетика комплексы һәм торак-коммуналь хуҗалык предприятиеләрендә аварияләргә бәйле гадәттән тыш хәлләрне бетерү буенча кышкы чорга “Стужа” чаралар планы нигезендә башкарыла.

Аварияне аның нәтиҗәләре характеры буенча муниципаль яки объект дәрәҗәсенә кертүне Россия Энергетика министрлыгының 2013 елның 12 мартындагы 103 номерлы боерыгы белән расланган климат шартларын исәпкә алып (җылылык чорына әзерлекне бәяләү кагыйдәләренә 3 нче кушымта), җылылык энергиясен кулланучыларны җылылык белән тәэмин итү ышанычлылыгы критерийларына таянып, эшләрне оештыручы хәл итә, алар нигезендә җылылык энергиясе чыганагында яисә җылылык челтәрләрендә авария вакытында барлык ремонт-торгызу чоры дәвамында түбәндәгеләр тәэмин ителергә тиеш (әгәр башка режимнар җылылык белән тәэмин итү килешүендә каралмаган булса):

җылылык энергиясен (җылыйөрткеч) беренче категория кулланучыларга тулысынча бирү;

җылылык энергиясен (җылыйөрткеч) икенче һәм өченче категория торак-коммуналь һәм сәнәгать кулланучыларына җылылык һәм вентиляция өчен

җылылык чорына әзерлекне бәяләү кагыйдәләре белән билгеләнгән күләмнәрдә бирү;

җылылык белән тәэмин итү шартнамәсе яклары тарафыннан килештерелгән пар һәм технологик кайнар су чыгымының авария режимы;

җылылык белән тәэмин итү шартнамәсе яклары тарафыннан килештерелгән сүндерелми торган вентиляция системаларының авария җылылык режимы;

җылылык чорына кайнар су белән тәэмин итүгә уртача тәүлеклек чыгым (аны сүндерү мөмкин булмаганда).

Әгәр эшләр җитәкчесе бәяләвенчә, авария башлану нәтиҗәсендә җылылык энергиясен кулланучыларны җылылык белән тәэмин итү ышанычлылыгы критерийлары үтәлсә, авария хәле объект дәрәҗәсенә карый.

Әгәр эшләр җитәкчесе бәяләвенчә, авария башлану нәтиҗәсендә җылылык энергиясен кулланучыларны җылылык белән тәэмин итү ышанычлылыгы критерийлары үтәлмәсә, авария хәле муниципаль дәрәҗәгә карый.

Җылылык белән тәэмин итү оешмасы электрон модельләштерүне кулланып (кирәк булганда) җылылык белән тәэмин итү объектларында авария хәлен бетерү буенча мөмкин булган техник чишелешләрне эшли.

Халыкка килеп туган хәл турында мәгълүматны ЕДДС Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтта урнаштыру юлы белән хәбәр итә.

Эшләргә өстәмә көч һәм средстволар җәлеп итү кирәк булган очракта эшләрне оештыручы бу хакта Зәй муниципаль районының гадәттән тыш хәлләр һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү комиссиясе рәисенә, ЕДДС диспетчерына хәбәр итә.

14. Авария нәтиҗәсендә гадәттән тыш хәл килеп чыгу куркынычы булганда (тәүлек буена һәм аннан да күбрәккә торак кварталларда халыкның тормыш-көнкүрешен тәэмин итүнең коммуналь-техник системаларын аварияле сүндереп тору, шулай ук критик түбән температура шартларында) эшләрне Зәй муниципаль районының гадәттән тыш хәлләр һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү комиссиясе координацияли.